**Казан шәһәре Башкарма Комитетының**
**2024 елның 10 июлендәге 2946 номерлы карары**

**Казан шәһәрендә «Казан триатлоны – 2024» чарасын үткәрү һәм чараны әзерләү һәм үткәрү чорында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында**

Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, халыкны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, Казанда спортны алга таба популярлаштыру максатларында, 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы «Юл хәрәкәте иминлеге турында», 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль законнарына һәм 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»гы Татарстан Республикасы Законына таянып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәрендә «Казан триатлоны – 2024» (алга таба – триатлон) ярышларын әзерләү һәм үткәрү вакытында әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә транспорт чаралары хәрәкәтен чикләргә:

- 2024 елның 10 августында 04.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр – Декабристлар урамыннан төшкән урында (Кремль дамбасыннан алып С. Хәким урамына кадәр, хәрәкәтнең бер юнәлешен туктатып тору);
- 2024 елның 10 августында 04.30 сәгатьтән 14.30 сәгатькә кадәр – С. Хәким урамы буенча (Декабристлар урамыннан алып Ф.Әмирхан урамына кадәр, хәрәкәтнең ике юнәлешен туктатып тору);

- 2024 елның 10 августында 04.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр – С. Хәким урамы буенча (Декабристлар урамыннан алып Әпсәләмов урамына кадәр, хәрәкәтнең ике юнәлешен туктатып тору);

- 2024 елның 10 августында 04.30 сәгатьтән 14.30 сәгатькә кадәр – С.Хәким урамы буенча (Ф.Әмирхан урамыннан алып Чистай урамы белән киселешкә кадәр, А.Козин һәм Нигъмәтуллин урамнары ягыннан үтәли үтеп чыгу мөмкинлеге белән хәрәкәтнең ике юнәлешен туктатып тору);

- 2024 елның 10 августында 04.30 сәгатьтән 14.30 сәгатькә кадәр – Чистай урамы буенча (С.Хәким урамыннан төшкән урыннан алып Чистай урамыннан төшкән урынга кадәр, хәрәкәтнең өч уң полосасын туктатып тору);

- 2024 елның 10 августында 04.30 сәгатьтән 14.30 сәгатькә кадәр – Чистай урамы буенча (Чистай урамыннан алып «Ак Барс Арена» стадионы тирәли әйләнә буенча хәрәкәткә төшкән урынга кадәр, хәрәкәтнең өч уң полосасын туктатып тору);

- 2024 елның 10 августында 04.30 сәгатьтән 14.30 сәгатькә кадәр – «Ак Барс Арена» стадионы тирәли эчке юл буенча (хәрәкәтне тулысынча чикләү);

- 2024 елның 10 августында 04.30 сәгатьтән 14.30 сәгатькә кадәр – аскы күпердә («Ак Барс Арена» стадионының эчке юлыннан хәрәкәт юнәлеше буенча Ямашев проспектына кадәр);

- 2024 елның 10 августында 07.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр – Пролетар урамы буенча (хәрәкәтнең ике юнәлешен туктатып тору);

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитетына (Л.З.Гарипов) триатлонны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтергә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров) транспорт предприятиеләренә юллар ябылу һәм җәмәгать транспорты маршрутлары үзгәрү турында хәбәр итәргә, дистанция маршруты буенча юл билгеләрен куюны, демонтажлауны, каплау һәм ачуны килештерергә, шулай ук троллейбусларның контакт челтәре терәкләрендә халыкка мәгълүмат бирү өчен юлны ябу схемаларын урнаштыруны килештерергә;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәләхетдинов) ярышлар маршруты буенча ремонт-төзелеш эшләрен үткәрү графигын төзәтергә, вакыйгага әзерләнгәндә керү юлларын һәм транспорт парковкасы урыннарын төзекләндерү буенча комплекслы чаралар үткәрергә, чара тәмамланганнан соң ярышны үткәрү урыннарына якын урам-юл челтәре объектларын җыештыруны тәэмин итәргә, яктырту терәкләрендә

халыкка мәгълүмат бирү өчен юлларны ябу схемаларын килештерергә, әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре белән берлектә йөк техникасы белән юлларны ябуга ярдәм итүне оештырырга;

1.5. Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләренә (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов) юлларны ябу өчен йөк техникасы бүлеп бирергә;

1.6. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әзерләү һәм үткәрү урыннарында җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга һәм Казан шәһәренең югарыда күрсәтелгән урам-юл челтәре участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында юл хәрәкәте иминлеге үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итәргә;

2.2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсенә (В.С.Филатов) катнашучыларга килешү нигезендә медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә;

2.3. Казан шәһәр Думасы аппаратының мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) массакүләм мәгълүмат чаралары аша спортчылар хәрәкәте вакытында урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләү кертелүе турында хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2024 елның 10 июлендәге 2946 номерлы
карарына 1 нче кушымта



Казан шәһәре Башкарма комитетының

2024 елның 10 июлендәге 2946 номерлы

карарына 2 нче кушымта




________________________________